ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32, E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

« 16 » июль 2021ел № 10

**«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 ст., Россия Федерациясе Җир кодексының 11,13 ст. нигезендә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын раслау турында» карарын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам..

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

Урта Курса авыл җирлеге
Башкарма комитетының
16.07.2021ел, №10
карарына кушымта

**«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасы**

**«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | РФ Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Заказчы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге |
| Программаны төп эшләүче | Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның төп максаты | Урта Курса авыл җирлеге җирләрен саклау һәм алардан рациональ файдалану буенча чараларны гамәлгә ашыру |
| Программаның билгеләнеше | Урта Курса авыл җирлеге җирләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2021-2023 еллар |
| Көтелгән нәтиҗәләр | Җирләрне саклау һәм рациональ файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, начарайган җирләрне торгызу, халыкның экологик иминлеген һәм аның тормыш сыйфатын күтәрү |
| Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору | Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны гамәлгә ашыру механизмы | Җирләрне саклау һәм рациональ файдалану буенча җир хуҗаларының һәм кулланучыларның эшчәнлеген координацияләү Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла. Программаны төгәлләштерү кирәк булган саен үткәрелә |
| Финанслау чыганаклары | Программаны үтәү муниципаль берәмлек бюджеты һәм оешмалар акчалары хисабына башкарыла |

**1. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсендә төп проблемалар һәм агымдагы торышына тасвирлама**

Җир-әйләнә-тирә мохитнең мөһим өлеше, аны куллану башка табигать объектлары: хайваннар, урманнар, үсемлекләр дөньясы, сулар, файдалы казылмалар һәм җир асты байлыкларының башка кыйммәтләре белән бәйле. Җирне куллану һәм саклаудан башка табигый ресурслардан файдалану мөмкин түгел. Җирнең хуҗасызлыгы якын киләчәктә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерәчәк, җирнең өске катламы - туфрак җимерелүгә, аның химик һәм радиоактив пычрануына гына китереп калмыйча, бөтен табигать комплексының экологик начараюына да китерәчәк.

«2021 - 2023 елларга Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм саклау» муниципаль программасы (алга таба - Программа) икътисадны ныгыту максатыннан, җир ресурсларыннан нәтиҗәле һәм рациональ файдалану һәм идарә итү буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган җирләрдән файдалану һәм саклау өчен уңай шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Җир фондының күбесен төрле максатларда куллану әйләнә-тирә мохит экосистемасының барлык чылбырының табигый бөтенлеген саклау буенча билгеле бер бурычлар йөкли. Табигатьтә барысы да үзара бәйләнгән. Шуңа күрә, бер буынның дөрес эшләвен бозу, урманмы ул, хайваннар дөньясымы, җир экосистемасының бөтенлеге бозылуга китерә.

Җирне рациональ файдаланмау, аңа хуҗасыз караш аның функцияләре бозылуга, табигый үзлекләре кимүгә китерә.

Җирләрне саклау җирдән нәтиҗәле файдаланганда гына уңышлы булырга мөмкин.

Иске Кырлай авыл җирлеге тотрыклы социаль-икътисади үсеше һәм анда яшәүчеләрнең имин экологик яшәеше проблемалары бүгенге этапта җирләрне саклау һәм куллану мәсьәләләрен хәл итү белән тыгыз бәйләнгән. Авыл җирлеге дәрәҗәсендә җирләрне саклау һәм куллану буенча җирле проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә мөмкин, өстәвенә, хәзерге вакытта яшәүче кешеләр генә түгел, киләчәк буын мәнфәгатьләрендә тулы, комплекслы һәм акыллы итеп хәл итәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителгән төрле җир кишәрлекләре бар.

Иң кыйммәтле җирләр-авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге авыл хуҗалыгы җирләре.

Җирлек территориясендәге көтүлекләр мәдәни-техник торышы буенча, нигездә, чиста. Көтүлекләр шәхси ярдәмче хуҗалыклар тарафыннан файдаланыла.

Көтүлекләргә, барлык куллануучыларны да исәпкә алсак, артык зыян килмәгән. Җирлектәге барлык көтүлекләрдә дә яшел үлән күп.

Гомүмән алганда, җирләрнең экологик торышы яхшы, әмма рөхсәтсез ясалган чүплекләр әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый һәм экологик хәлне катлауландыра.

**2. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның максатлары, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре, сроклары һәм этаплары**

Җирлек территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль сәясәтнең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенең законлылыгы һәм ачыклыгы, хисаплылык һәм контрольлек, нәтиҗәлелек.

Муниципаль программаның максаты-җирләрне һәм туфракларны пычрату, юкка чыгару, начарайту, бозу һәм башка тискәре йогынты ясамау, шулай ук җирләрне рациональ файдалануны, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшыртуны тәэмин итү.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге эшчәнлекне оптимальләштерү;
- җирләрдән файдалану һәм саклау нәтиҗәлелеген арттыру, җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны оештыру;
- яшел үсентеләрне саклау һәм торгызу;
- җирләрне инвентаризацияләү.

Җирләрне инвентаризацияләү җирләрне начарайту, пычрату, чүпләү, бозу, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысын булдырмау, максатчан кулланылмаган җир кишәрлекләренең, җирләрнең башка тасвирламаларының рөхсәт ителгәнчә файдаланылмавын ачыклау максатыннан башкарыла.

Әлеге Программаны тормышка ашыру җирдән файдалануны тәртипкә салуга, яңа җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертүгә, авыл җирлегенең инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыруга, икътисадны үстерүгә, җирләрне нәтиҗәле файдалануга һәм саклауга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә:

1) торак пунктларны төзекләндерү;
2) җирләрнең сыйфатын   яхшырту;
3) җирләрне нәтиҗәле файдалану тәэмин ителәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру срогы-2021-2023 еллар.

### 3.Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклау һәм файдалану нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар планлаштырылды.

| N | Чара исеме | Финанслау (финанслау чыганагын күрсәтеп), мең сум | Башкаручы | Үтәү срогы | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Чокырларның өске катламын ныгыту | Оешмаларның, шәхси затларның, җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 2. | Гомумтаралган файдалы казылмалар карьерларына инвентаризация үткәрү. Әлеге карьерларны конкрет оешмаларга беркетү. Аларны рекультивацияләү проектларын эшләү | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2023 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 3. | Карьерларга рекультивация үткәрү | Оешмаларның, шәхси затларның, | Карьерлардан файдаланучылар | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | җирдән файдалануч ыларның үз акчалары | | | |
| 4. | Шәхси буаларны, башка гидротехник су объектларын ачыклау һәм әлеге корылмаларны конкрет милекчеләр тарафыннан тикшерү | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2023 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 5. | Җирдән файдалану, линия объектлары корылмалары, юл челтәре, чикләнгән файдалану җирләре, сыйфат күрсәткечләре белән җирләрнең бердәм базасын формалаштыру һәм алып бару | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2023 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 6. | _____________ авыл җирлеге торак пунктлар территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү ________ | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 7. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре үсүдән саклау буенча чаралар үткәрү һәм зарарлы организмнардан саклау | Җирдән файдалануч ыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Руководители организации, частные лица |
| 8. | Хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысына дучар ителгән җирләрне яхшырту һәм торгызуны тәэмин итү | Җирдән файдалануч ыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Руководители организации, частные лица |
| 9. | Рөхсәтсез төзелеш фактларын ачыклау | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 10. | Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану тәртибен җайга сала торган норматив- | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | хокукый актларның, шулай ук Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану тәртибен җайга сала торган башка хокукый актларның үтәлешен гамәлгә ашыру | | | | |
| 11. | Авыл җирлеге җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану режимының үтәлешен контрольдә тоту | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 12. | Авыл җирлеге территориясен чүп-чардан, шул исәптән рөхсәтсез чүплекләрдән арындыру буенча даими чаралар оештыру | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 13. | Су эрозиясенә дучар булган урыннарда куаклар һәм агачлар утырту, торак пунктлар эчендә ярларны ныгыту | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 14. | Авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителгән җир кишәрлекләреннән файдаланылмаган һәм кулланылмаган җирләрне ачыклау | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 15. | Җир кишәрлегенә хокукны тиешенчә файдаланмау сәбәпле, хокукны туктату турындагы материалларны судка җибәрү | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 16. | Җир кишәрлекләрен экологик хәл шактый начараюга китерә торган куллану фактларын ачыклау | Финанслау таләп ителми | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 17. | Ашламалар, агулы химикатлар һәм башка куркыныч химик яки биологик матдәләр белән эш итү кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә туфракның уңдырышлы катламын агулау, пычрату, бозу яки юк итү фактларын ачыклау | Финанслау таләп ителми | Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 18. | Махсус шартлары булган җир кишәрлекләрен файдалануны, аларны кулллануны (саклау, санитар – сак, су саклау һәм башка зоналарны) тикшереп торуны гамәлгә ашыру | Финанслау таләп ителми | Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 19. | Җир законнарын бозу фактлары буенча материалларны РФ законнары белән каралган җаваплылыкка тарту өчен дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Арча һәм Әтнә районнары буенча муниципальара бүлегенә җибәрү | Финанслау таләп ителми | Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |